| | |
|---|---|
| **СОВЕТ**<br>**Кулегашского сельского поселения**<br>**Агрызского муниципального района**<br>**Республики Татарстан** | **Татарстан Республикасы**<br>**Әгерҗе муниципаль районы**<br>**Күләгәш авыл җирлеге**<br>**СОВЕТЫ** |
| **РЕШЕНИЕ** | **КАРАР** |

1 октября 2018 г. Күләгәш авылы 41-1

Күләгәш авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләү турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокуклары һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, «Җирле референдум турында» 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 18 статьясы, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы «Күләгәш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 10, 11 статьялары нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен раслау турында» 2013 ел, 22 ноябрь, 909 нчы карары, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Күләгәш авыл җирлеге Советының «Җирле референдум үткәрү инициативасы турында»2018 елның 28 августындагы 39-3 номерлы карары, Күләгәш авыл җирлеге Башкарма комитетының 2018 елның 28 августындагы 8 номерлы «Җирле референдум үткәрү инициативасы турында» карары нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Күләгәш авыл җирлеге Советы **карар бирде**:

1.2018 елның 18 ноябренә Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Күләгәш авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салымын кертү мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләргә.

2.Җирле референдумга чыгарыла торган түбәндәге сорауны расларга:

«I группа инвалидлар, торып укучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына ашыгыч хезмәткә чакырылучылардан, иректән мәхрүм ителгәннәрдән кала, раслаучы документлар булганда, Күләгәш авыл җирлегендә теркәлгән, балигъ булган һәр гражданга 2019 елда үзара салымны 300 сум күләмендә кертергә һәм шул акчаларны түбәндәге җирле мәсьәләләрне хәл итәргә юнәлтергә Сез ризамы:

1.Күләгәш авыл җирлеге территориясендә зиратларны карап тотуны оештыру.

2.Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә гомуми файдаланудагы юлларны ремонтлау һәм хезмәт күрсәтү.

3.Авыл җирлеге чикләрендә беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү (янгын сүндерү машинасын карап тоту, ашыгыч килешү буенча штаттан тыш хезмәткәргә (шоферга) түләү.

ӘЙЕ ЮК».

3.Әлеге карарны Күләгәш авыл җирлеге Советының мәгълүмати стендларында, http://pravo.tatarstan.ru Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында һәм http://agryz.tatarstan.ru Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Әгерҗе муниципаль районы сайтында урнаштырырга.

4.Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Совет Рәисе Ю.Н.Васильев